КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 апрель г.Казань № 321

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган юридик хокуклы өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләрне булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган юридик хокуклы өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләрне булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 март, 157 нче, 2017 ел, 8 декабрь, 961 нче; 2018 ел, 5 апрель, 208 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1284 нче, 2020 ел, 19 август, 708 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

икенче абзацта «4» санын «6» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «6» санын «8» санына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «8» санын «10» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган юридик хокуклы өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләрне булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәдә:

2.1 пунктта «(алга таба - гариза)» сүзләреннән соң «, анда кандидатның гаилә составы турында белешмәләр күрсәтелә» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктта:

2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктчага «, шулай ук кандидатның яшәү урыны булып торучы торак урынның гомуми мәйданы күләме турында белешмәләр булган» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) гаризада күрсәтелгән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлардагы каршылыклы һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр булу.».

2. Бу карар (әлеге карарның 2022 елның 1 июленнән үз көченә керә торган 1 пунктның икенче - бишенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин